ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2023 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад хакында

2023 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында С.Х. Сабурская докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында С.Х. Сабурская докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү өлкәсендә законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына 2023 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында докладтагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2336-VI ДС